Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Анатыш авыл җирлеге Советы

КАРАР №V-1

Анатыш авылы 2026 елның 21 гыйнвары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советының "Җирле салым суммалары өлешендә бурычларны түләргә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" XXXI-1 номерлы 28.04.2023 карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында" 28.11.2025 № 425-ФЗ Федераль законы нигезендә, "Анатыш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын күздә тотып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Анатыш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советының "Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләргә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" 28.04.2023 XXXI-1 номерлы карарына кертелсен (18.06.2024 № XLVII-1, 30.10.2024 № LIII-1) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасы түбәндәге редакциядә язылсын:

"1) Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә физик зат үлгән яки ул үлгән дип игълан ителгән (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очракта гына):

Россия Федерациясе Салым кодексының 14 статьясының 3 пунктында һәм 15 статьясының 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар, җыемнар, иминият взнослары, штрафлар, процентлар буенча бурычлар өлешендә;

Россия Федерациясе Салым кодексының 14 статьясының 3 пунктында һәм 15 статьясының 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча бурычлар өлешендә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта, аның мирас милеге бәясеннән артыграк күләмдә;

Россия Федерациясе Салым кодексының 14 статьясының 3 пунктында һәм 15 статьясының 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча бурычлар өлешендә, мондый физик зат үлгән көннән өч ел узгач һәм салым

органында мондый милекне мирас итү фактлары турында мәгълүмат булмаган очракта, аның мирас милеге бәясеннән артмаган күләмдә;".

2, Бу карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3, Бу карар Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Анатыш авылы, Клубная урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Анатыш авыл җирлеге махсус мәгълүмат стендларында урнаштырылсын; Балык Бистәсе районы, Татарстан Республикасы Шиланка урамы, Яр буе урамы, 1 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru.

4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Анатыш авыл җирлеге Башлыгы: К. К. Җамалиев